# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"17" ноябрь 2022 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 16 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2022 елның 17 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, тавыш бирү хокукына ия булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Кышлау авылы территориясен чистарту (үлән чабу);
2) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү;
3) урамга яктырткычлар сатып алу;
4) Кышлау авылы зираты юлын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу (килешү буенча хезмәт хакы түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 265 (ике йөз алтмыш биш) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 156 (йөз илле алты) кеше, бу 58,86 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 156 (йөз илле алты) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. "Сез 2023 елда Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, тавыш бирү хокукына ия булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Кышлау авылы территориясен чистарту (үлән чабу);
2) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү;
3) урамга яктырткычлар сатып алу;
4) Кышлау авылы зираты юлын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу (килешү буенча хезмәт хакы түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Кашшапов А.Х.